# Визитная карточка

**Самой дружной семьи – семьи Хафизовых, которая проживает в самом красивом уголке Земного шара, в Актанышском районе Республики Татарстан, с.Актаныш, ул.Тукая, д.18.**

Здравствуйте, дорогие друзья! Я хочу представить Вам нашу большую и дружную семью, где много людей: папа, мама, сестра, братишка, две бабушки, дедушка, и конечно же я. Наша работа называется “Мой дом – моя крепость”. Стихи – мамины, а презентацию я сделала сама. В прошлом году я также участвовала в этом конкурсе и заняла почетное II место. Тогда работа была совсем другая – о родном крае. Спасибо Вам огромное!

С уважением, Айсылу Хафизова, 2б класс.

# Безнең

# гаилә



**Актаныш районы Яңа Әлем авылының никахлашу сараена горур атлап төз гәүдәле егет керә. Аның янәшәсендә, аңа бераз сыена төшеп, үз буйсынына үлчәп тегелгән туй күлмәге кигән кәләш атлый. Кулында ал роза чәчәкләре. Күзләр үз парын эзләп табып, бер-берсенә карашып алырга да өлгерә. Сөю ташып торган күзләр шул рәвешле кабат-кабат очраша. Пар үгәрченнәрдәй яшәргә сүз куешып безнең олы тормыш юлына кереп барышыбыз. 1997нче елның 8нче маенда Усы авылы егете Хафизов Айрат белән Яңа Әлем кызы Хасанова Зифаның тормыш сукмаклары бергә тоташа.**

**Исемебез гел янәшә**
**Ай белән кояш кебек**
**Бәхетлеләр арасында**
**Безгә тиң булмас кебек!**

**1999 нчы елның 8нче маенда бердәм, тату гаилә булып яши башлавыбызга 2 ел тулды. Нәкъ шул көнне-туй көнебездәге кебек кояшлы, ямьле язгы көндә, бар табигать кышкы йокыдан уянып яшеллекә, ак чәчәкләргә төренгән көндә, тәүге мәхәббәт җимешебез-энҗе бөртегедәй кызыбыз туды.**
**Өебезгә нур өстәп шатлыклы зур бәхет алып килгән кызыбызга Зилә дип исем куштык.**




**Галибанә яктырып**
**Ал таң аткан чагында,**
**Сандугачлар җиһанга**
**Моң тараткан чагында,**

**Җанлыдан җан яралды.**

**Чәчәкләр баш калкытып,**
**Нурга күмелгән мәлдә,**
**Бар табигать җанланып,**
**Җырга төренгән мәлдә,**
**Җанлыдан җан яралды.**



**2002нче елның 23енче декабрендә-бар табигать: урманнар, кырлар ап-ак кар юрганына төренеп сихри гүзәллеккә күмелгән вакытта безнең икенче кызыбыз дөньяга аваз салды. Без аңа сылу, чибәр, матур, изге, ак, якты, нурлы, акыллы бул сын дип Айсылу исемен куштык.**

**2007нче елның 21нче октябрендә кызларыбыз Зилә белән Айсылуга зарыгып көткән энекәш алып кайттык. Нәсел агачын дәвам итүче улыбызга нык билле, дәү, таза, батыр йөрәкле, кыю булсын дип Булат исемен куштык.**

**Матур апам уң якта,**
**Чибәр апам сул якта.**
**Ә мин тәти малай булам-**
**Ник әле мактанмаска!**



**Җиргә, күккә, тирә-юньгә**
**Яңа аваз таралды.**
**Шабыр тиргә төшкән ана**
**Бер рәхәт сулыш алды...**
**Бар матурдан матуррак,**
**Кыйммәтледән кыйммәтлерәк,**
**Үз җаныннан газизрәк**
**Бала тудырды Ана.**

**Гаилә тормышыбызның нигезе.Гаилә нык,тату икән, димәк, җәмгыять тә нык, тату дигән сүз.Әти-әни анның тоткасы булса, балалар-гаиләнең көзгесе.Әгәр тотка купмасын, көзге ватылмасын дисәң, бер-берегезне саклап, рәнҗетми, хөрмәт белән яшәргә кирәк. Якты дөньяга аваз салган көннән башлап, безнең янда иң якын кешеләребез-әти-әниебез.Алар безгә җан җылысы, ата-ана мәхәббәте бирә, беренче адымнарыбызны алар ярдәмендә ясыйбыз.**




**Гомер буе язсын иде безгә**
**Әти, әни диеп дәшәргә.**
**Кайгы күрми, бәхет, шатлык белән**
**Бергә-бергә озак яшәргә.**
**Иң кадерле кешеләребез сез,**
**Әтием һәм әнием.**
**Сез булганга, без бәхетле**
**Тыныч,рәхәт яшибез!**



**Җылы куллар тирбәткәннәр**
**Салып безне бер бишеккә**
**Ходай биргән туганлыкны**
**Югалтмыйк без, атмыйк читкә.**

**Без бер чишмә суын эчеп**
**Бер тамырдан үскән гөлләр,**
**Тормыш юлын бергә үткән**
**Җан сердәшләр: апа-сеңел.**



***Балалар – безнең иң зур байлыгыбыз!***





*Туганнарың күп булу –*

*үзе зур бәхет!*





**Әбекәй, бабакай, әнкәем – алтыным**
**Минем иң якыннарым –**
**Яратам , яратам мин аларны!**

